**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**

**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 366-48 «24» август 2020 ел

Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 188-28 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында " карары белән расланган, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (23.05.2019 ел №259-36 карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" карары нигезендә, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү максатыннан

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. 2020 елның 01 октябреннән, Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 188-28 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" (23.05.2019 №259-36 карар редакциясендә) карары белән расланган, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен арттырырга.

2. Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 188-28 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" (23.05.2019 №259-36 карар редакциясендә) карары белән расланган, бюджет өлкәсе хезмәткәр ләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертрегә:

- 1.4 пунктта. «11 163,00» санын «11498,00» санына алмаштырырга.

3.Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәисе М. З. Шәйдуллин